Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
жашур авыл җирлеге советы

КАРАР

2022 елның 10 ноябре № 23

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Важашур авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы, гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясы нигезендә Важашур авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Важашур авыл җирлеге Советының 2014 елның 09 апрелендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Важашур авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы, гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе турында нигезләмәгә (Важашур авыл җирлеге Советының 2016 елның 01 октябрендәге 25 номерлы, 2018 елның 17 сентябрендәге 20 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5.1.А пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1.А. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләүдән түбәндәге категория затлар азат ителә:
- 1 төркем инвалидлары;
- көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар);
-18 яшькә кадәге 4 яки аннан да күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләр;
- 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан өлкәнрәкләр;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары».

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып халыкка җиткерергә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Важашур авыл җирлеге башлыгы П.Л. Иванов